| | |
|---|---|
| ГЛАВА<br>БАГАЕВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>КАЙБИЦКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>БАГАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10 нчы ноябрь, 2023 ел Багай ав. № 1

Гражданнарның үзара салым акчаларын
кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча
Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль
районы Багай авыл җирлегенең Багай авылында
гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законының 25.1,56 маддәләре,«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Багай авыл җирлеге Уставының 22 маддәсе нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. 2023 елның 21 ноябренә 11 сәгать 00 минутка Багай авылы мәдәният йортында: Багай авылы, Үзәк урамы, 28 йорт. адресы буенча урнашкан, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Багай торак пунктында үзара салым алып бару мәсьләләре буенча гражданнар җыенының ***беренче этабын*** билгеләргә.

2. 2023 елның 21 ноябренә 13 сәгать 00 минутка Багай башлангыч гомуми белем бирү мәктәбендә: Багай авылы, Мәктәп урамы, 4 йорт. адресы буенча урнашкан, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Багай торак пунктында үзара салым алып бару мәсьләләре буенча гражданнар җыенының ***икенче этабын*** билгеләргә.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2024 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының яшәү урыны буенча Багай авыл җирлеге Багай торак пункт территориясендә теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

*а) җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:*

- материаллар сатып алып, урамнарны яктыртуны ремонтлау;
- авыл җирлегендә торак пунктлардагы рөхсәтсез чүплекләрдән территорияләрен чистарту;

- йорт номерлары һәм урам исемнәре белән күрсәткечләрне торак йортларның адрес хуҗалыклары норматив хәлгә китерү.

*б) җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:*

- материаллар сатып алып, су күтәрү манараларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү;

- материаллар сатып алып суүткәргеч челтәрләрен карап тоту;

*в) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль*

- авыл җирлеге торак пункты территориясен карап тоту.

*г) беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү:*

- Янгын сүндерү машинасын, җиһазларны, биналарны һәм ДЕПО хезмәткәрен тоту.»

« РИЗА» «КАРШЫ»

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Багай авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка таратырга һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Багай авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Багай авыл җирлеге башлыгы Р.Ф.Кузнецова